# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Зирекле авылында 2022 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2022 елның «22» ноябреннән № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Зирекле авылындагы гражданнар җыены нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә алынучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Мәктәп, Вахитов урамнары буенча юлларга вак таш салу (вак таш сатып алу, китерү, бушату, тарату, катоклау, грейдер ярдэмендә тигезләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- зират территориясен төзекләндерү (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабып узу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда: (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Ж.Г. Гайфетдинов

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ